"Татарстан Республикасы
Мөслим муниципаль районы
мәгариф идарәсе" муниципаль
казна учреждениесе

Муниципальное казенное учреждение
"Управление образования
Муслюмовского муниципального района
Республики Татарстан"

**Адрес:** 423970, РТ, Муслюмовский район, с.Муслюмово, ул.Гагарина, 11
**Тел.:** (85556) 2-57-30, 2-43-35 (факс) **e-mail:**roo.mus@tatar.ru

**П Р И К А З**

№ 291 "10" августа 2018г

Об утверждении Положения
районного конкурса учителей
«Лучшее методическое портфолио»

На основании плана МКУ «Управления образования Муслюмовского муниципального района РТ» на 2018-2019 учебный год, государственной программы Республики Татарстан «Сохранение, изучение и развитие государственных языков Республики Татарстан и других языков в Республике Татарстан на 2014 – 2020 годы» и в целях создания условий профессиональной компетенции развития учителей татарского языка и литературы, приказываю:

1. Провести конкурс учителей «Лучшее методическое портфолио» с 01 сентября по 21 декабря 2018г.

2. Утвердить положение о конкурсе (Приложение 1).

3. Контроль за исполнением приказа возложить на Шаймарданову Н.А., методиста управления образования.

Начальник МКУ УО: Р.Т.Демидов

С приказом ознакомил(ась)ся:
«10» августа 2018г. ________ Шаймарданова Н.А.

**Кушымта №1**

**Укытучыларның районкүләм «Иң яхшы методик портфолио» бәйгесе турында**

**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми мәгълүмат

1.1. Укытучыларның районкүләм "Иң яхшы методик портфолио" бәйгесе (алга таба – Бәйге), Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе планы нигезендә, «2014-2020 нче елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Татарстан Республикасы Дәүләт программасын тормышка ашыру максатыннан үткәрелә.

1.2. Портфолио — ул укытучының педагогик эшчәнлек нәтиҗәләрен теркәү, туплау һәм бәяләүнең бер алымы, һөнәри үсешнең заманча методларыннан берсе. Портфолио мөгаллимгә үз казанышларын тагын да киңрәк һәм төрлерәк итеп тәкъдир итәргә, белем бирү траекториясен планлаштырырга, күзәтергә һәм кирәк вакытта төзәтергә мөмкинлек бирә, һөнәри үсеш дәрәҗәсен исбатлау өчен дәлил һәм чираттагы аттестация өчен нигез булып тора. Портфолио төзү укытучыга үз белемен күтәрү темасы буенча эшчәнлегенә, аның характерына бәя бирергә, иҗади һәм һөнәри үсешен объектив нәтиҗәләргә таянып күзәтергә, нәтиҗә ясарга өйрәтә, рефлексия (үзбәя) күнекмәләре формалаштырырга ярдәм итә.

1.3. Бәйгенең *<u>максаты</u>* - татар теле һәм әдәбияты укытучыларының һөнәри компетецияләре үсешенә шартлар тудыру.

Бәйгенең *<u>бурычлары</u>*:

- методик портфолионы формалаштыру һәм тәкъдир итүнең уңай тәҗрибәсен ачыклау;
- һөнәри инициативаны үстерү, аңа булышлык итү;
- һөнәри үзүсешкә ихтыяҗ формалаштыру;
- югары дәрәҗәдәге иҗади мотивациягә шартлар тудыру;
- гомуми төп, урта белем бирү оешмаларында белем бирүче укытучыларны һөнәри яктан үстерү юлларын билгеләү, тәҗрибә уртаклашу.

1.4. Бәйгенең оештыручысы - Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсе.

## 2. Бәйгедә катнашучылар

2.1. Бәйгедә Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында эшләүче туган теле һәм әдәбияты укытучылары катнаша ала.

2.2. Бәйгедә туган тел (татар теле, әдәбият) предметын укыту белән мәктәп директоры, директор урынбасары, педагог-оештыручы, педагог-китапханәче, башлангыч сыйныф укытучысы вазифасын алып баручы педагоглар да катнаша ала. Бу очракта аларның туган тел (татар теле, әдәбият) предметы буенча тупланган материаллары гына кабул ителә.

2.2. Бәйгедә катнашучылар бәйге таләп иткән барлык материалларны әзерлиләр һәм нигезләмәдә билгеләнгән вакытта тапшыралар.

## 3. Бәйгене оештыру һәм үткәрү тәртибе

3.1. Мөгаллимнең методик портфолиосы тупланма-папка рәвешендә *кушымтада* тәкъдим ителгән мәҗбүри эчтәлеккә таянып формалаштырыла. Моннан тыш укытучы аңа үзе кирәк дип тапкан материалларны да өсти ала. Портфолиода соңгы 5 елның (2013-2018 нче уку еллары) нәтиҗәләре туплап тәкъдим ителә.

3.2. Бәйгегә тәкъдим ителүче материал 2018 нче елның 21 нче декабренә кадәр Мөслим муниципаль районы мәгариф идарәсенә тапшырыла.

3.3. Бәйгенең жюри составын мәгариф идарәсе билгели.

3.4. Бер атна дәвамында эксперт комиссиясе билгеләнгән критерийлардан *(карагыз: нигезләмә - 3.7.)* чыгып бәя бирә, нәтиҗә чыгара, җиңүчеләрне билгели. Карар беркетмәгә теркәлә, үзгәрешсез кабул ителә.

3.5. Бәйгедә җиңү яулаган укытучыларга мәгариф идарәсенең 1 нче, 2 нче һәм 3 нче дәрәҗәдәге дипломнары тапшырыла. Җиңүчеләрне бүләкләү вакытын һәм урынын оештыручылар хәл итә.

3.6. Иң яхшы портфолио үрнәкләре татар теле һәм әдәбияты укытучыларының район методик берләшмәсе утырышында күргәзмәгә куелып, башка мөгаллимнәргә алар белән танышу мөмкинлеге тудырыла.

3.7. Бәйгегә тәкъдим ителгән эшләр түбәндәге *критерийлар* буенча бәяләнә:

- үзмониторингның системалы һәм регуляр (вакытында тутырылган) булуы – 5 балл;
- мәгълүматның дөрес һәм объектив булуы – 5 балл;
- мәҗбүри булырга тиешле мәгълүматның (*карагыз: кушымта*) тулы булуы – 5 балл;
- материалның структурага салынган һәм ачык аңлаешлы булуы – 5 балл;
- аңлатма язуларының логик яктан дөрес, кыска һәм төзек булуы – 5 балл;
- эш нәтиҗәләренең күрсәтмәле булуы – 5 балл;
- пөхтә һәм эстетик яктан зәвыклы булуы – 5 балл;
- тәкъдим ителгән материалның тематик яктан бөтен һәм тәгәлләнгән булуы – 5 балл;
- иҗади якын килү, креативлык - 5 балл.
- эш нәтиҗәләренең динамикасын күрсәтә белү – 5 балл.

Җыярга мөмкин булган баллар саны – 50 балл.

3.8. Бәйгенең координаторы: Шәймәрданова Н.Ә.
Хәбәрләшү өчен телефон: 8(85556)2-40-49
Электрон почта: nurania.shai@tatar.ru

***Кушымта.***

**Методик портфолионың төзелеше һәм эчтәлеге**

**1. Укытучы турында гомуми мәгълүмат.**

*Бу бүлектәге материаллар укытучының төрле өлкәдә алган уңышларын, укытучының шәхси үсешен гомуми яктан күрсәтә.*

- титул бите;
- укытучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туу вакыты;
- белеме (уку йортының исеме, кайчан тәмамлаган, диплом буенча белгечлек һәм һәм квалификация, диплом номеры, күчермәсе);
- эш стажы (гомуми/белгечлек буенча);
- белем күтәрү (структураның исеме, белем күтәрү урыны, вакыты, темасы, сәгать саны, күчермәсе);
- төрле дәрәҗәдәге мактаулы исемнәрне дәлилләүче документлар күчермәсе;
- аеруча әһәмиятле бүләкләр (грамоталар, мактау хатлары, дипломнар күчермәсе) исемлеге;
- башка документлар (теләк буенча).

**2. Белем бирү нәтиҗәләре.**

*Бүлек материалы укытучы эшчәнлегенең соңгы 5 елындагы үсеш, уңышларын чагыштырып карарга ярдәм итә.*

- укытучы белем биргән сыйныфлар һәм алардагы укучылар саны;
- татар теле һәм әдәбияты бенча өлгереш, сыйфатлы өлгереш нәтиҗәләре;
- укыту предметы буенча уртача балл (билге);
- контроль кисем нәтиҗәләре (административ дәрәҗә һәм югарырак);
- олимпиада нәтиҗәләре буенча санлы мәгълүмат (катнашучылар саны, нәтиҗәләр);
- йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре;
- бәйге нәтиҗәләре буенча санлы мәгълүмат (катнашучылар саны, нәтиҗәләр);
- мәктәпне аерым үрнәктәге аттестат һәм медальгә тәмамлаучы укучыларының саны, исемлеге;
- белгечлек буенча югары уку йортларында белем алу турында мәгълүмат ( Ф.И.О, уку йорты, тәмамлаган елы);
- башка документлар (теләк буенча).

**3. Фәнни-методик эшчәнлек.**

*Әлеге бүлектә методик яктан өлгергәнлек һәм өзлексез һөнәри үсеш турында дәлилләр тупланa..*

- методик тема, аның буенча эш планы/һөнәри үсеш програмасы;
- сайланган укыту программалары һәм методик әдәбиятны нигезли белүче документлар (кайсы сыйныфта нинди программа, нинди дәреслекләр белән укытыла, эш программаларының таләпләргә туры килүен дәлилли белү һ.б.);
- белем бирү нәтиҗәләрен бәяләү өчен сайланган педагогик диагностика чараларын нигезли белүне күрсәтүче материаллар (арадаш аттестация, агымдагы язма эшләрнең диагностикага корылган булуын күрсәтүче дәлилләр һ.б.);
- белем бирү процессында заманча (шул исәптән мәгълүмати-коммуникатив) педагогик технологияләрдән файдалануны раслаучы материаллар;
- укучылар белән адреслы эшләү турында мәгълүмат, материаллар (сәләтле укучылар, йомшак өлгерүчеләр, авыр гаиләдә тәрбияләнүче балалар, чит илләрдә күчеп килгән балалар, шәхси шөгыльләнү яки авыру балалар белән эшләү өчен материаллар һ.б.)
- инновацион эшчәнлек буенча материаллар (булса - кайсы инновацион мәйданчыкка беркетелгән, нинди тема буенча эшли, эшчәнлек нәтиҗәләре, исбатлаучы документлар)

• һөнәри берлекләр эшчәлегендә катнашу: район методик берләмәсе эшчәнлегендә, мәктәп методик берләшмәләрендә, эксперт советында, һөнәри үсеш буенча грантларны тормышка ашыру (чыгышларның, чараларның датасы, темасы һ.б.);
• методик үзәкләр һ.б. учреждениеләр белән хезмәттәшлек итү (булса);
• ачыклар дәресләр, мастер-класслар күрсәтү, һөнәри бәйгеләрдә, фәнни-гамәли конференцияләрдә, семинарларда катнашу турында мәгълүмат, чыгышларның исемнәре, вакыты, урыны һ.б.;
• авторлык программалары, электив курслар, шәхсән язылган методик эшкәртмәләр, дидактик, диагностик турында мәгълүмат, аларга язылган рецензияләр һ.б.
• башка документлар (теләк буенча).

**4. Укыту предметы буенча дәрестән тыш эшчәнлек.**

*Бүлек материалы укучыларныңпредмет буенча шәхси үсеш нәтиҗәләрен күзәтеп, туплап барырга, анализларга ярдәм итә.*

• укучылар тарафыннан башкарылган иҗади эшләр, рефератлар, проектлар, фәнни-тикшеренү эшләренең темалары, нәтиҗәләре;
• иҗади һәм интллектуаль бәйге нәтиҗәләре (ФИО, бәйге исеме, нәтиҗәләр)
• иҗтимагый проектларда катнашу, нәтиҗәләр;
• дәрестән тыш эшчәнлек (факультатив, электив курс, түгәрәк, студия һ.б.) программалары белән эшләү турында мәгълүмат, материаллар;
• башка документлар (теләк буенча).

**5. Иҗтимагый танылу.**

*Әлеге бүлектә мөгаллимгә иҗтимагый оешмалар, әти-әниләр, һөнәри берлек әгъзалары һ.б. биргән бәя, һөнәри активлыкны, педагогик тәҗрибә алмашуны раслаучы документлар туплана.*

• һөнәри һәм жирле периодик басмаларда, җыентыкларда чыккан мәкаләләр, чыгышлар турында мәгълүмат (кайда, кайчан басылуы), аларның тезислары, күчермәләре;
• конференцияләрдә, семинарларда, предмет берләшмәләрендә ясаган чыгышларның тезислары, текстлары һ.б.;
• һөнәрдәшләр, администрация вәкилләре, иҗтимагый оешма җитәкчеләре, фән кешеләре, әти-әниләр, укучылар һ.б. язган бәяләмәләр, мәкаләләр, рецензияләр, белешмәләр һ.б.;
• башка документлар (теләк буенча).